МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 176/о

ПРИКАЗ — БОЕРЫК

«01» 12 2022

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июнендәге 69/о номерлы боерыгы белән расланган Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июнендәге 69/о номерлы боерыгы белән расланган Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлеккә (Э.Ю.Латыйпова), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министрлыгының
«_01_»____12___2022
№_176/о_боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июнендәге 69/о номерлы боерыгы белән расланган Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

3 бүлекнең 3.5.2.1 пунктында унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызига формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гаризада электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында Министрлык билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда гаризаның электрон формасындагы кырларны төгәлсез тутыру очрагы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткереп, хәбәр ителә.»;

3.6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Министрлыкның ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи заты әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләрне әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, сорала торган документлар исемлеге:

1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, гавами сервитутны билгеләү турында карар турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә җибәрелә;

2) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә туры килүе турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы бәяләмәсе. Рәсми мөрәҗәгать объектка дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вәкаләтле органга җибәрелә;

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.»;

3.6.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2. Әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән (ике эш көне –дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алганда) артмаска тиеш. Процедураның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерүләр тора.

Белешмәләрне кулலануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
3 нче кушымта

Кемгә: ____________________
(төзүченең атамасы (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

гражданнар өчен, оешманың тулы исеме – юридик затлар өчен), аның почта индексы һәм адресы, электрон почта адресы)

# ОБЪЕКТНЫ ФАЙДАЛАНУГА КЕРТҮГӘ РӨХСӘТ

| | |
|---|---|
| 1 нче бүлек. Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт реквизитлары | |
| 1.1. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт әзерләү датасы <2>: | |
| 1.2. Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт номеры <3>: | |
| 1.3. Органның (оешманың) атамасы <4> : | |
| 1.4. Үзгәрешләр яки төзәтмәләр кертү датасы <5>: | |
| 2 нче бүлек. Төзүче оешма турында мәгълүмат | |
| 2.1. Физик зат яки шәхси эшкуар турында мәгълүмат: | |
| 2.1.1. Фамилиясе: | |
| 2.1.2. Исеме: | |
| 2.1.3. Атасының исеме <6>: | |
| 2.1.4. Салым түләүченең тәңгәллек номеры: | |
| 2.1.5. ОГРНИП <7>: | |
| 2.2. Юридик зат турында белешмәләр: | |
| 2.2.1. Тулы атамасы <8>: | |
| 2.2.2. Салым түләүченең тәңгәллек номеры: | |
| 2.2.3. ОГРН: | |
| 3 нче бүлек. Капиталь төзелеш объекты турында мәгълүматлар | |
| 3.1. Проект документлары нигезендә капиталь төзелеш объектының (этапның) исеме: | |
| 3.2. Капиталь төзелеш объектына карата башкарылган эшләр төре <9>: | |
| 3.3. Капиталь төзелеш объекты урнашкан адрес (урын) <10> | |
| 3.3.1. Россия Федерациясе субъекты: | |
| 3.3.2. Муниципаль район, муниципаль округ, шәһәр округы яки шәһәр эчендәге территория (федераль | |

| | |
|---|---|
| әһәмияттәге шәһәрләр өчен) Россия Федерациясе субъекты составында, федераль территория: | |
| 3.3.3. Муниципаль район составында (муниципаль район өчен) яки шәһәр эчендәге район составында (федераль территорияләрдә урнашкан биналар, корылмалар, корылмалардан тыш) шәһәр яки авыл җирлеге: | |
| 3.3.4. Торак пунктның төре һәм исеме: | |
| 3.3.5. Планлаштыру структурасы элементының исеме: | |
| 3.3.6. Урам-юл челтәре элементының исеме: | |
| 3.3.7. Бинаның (корылманың) төре һәм номеры: | |
| 4 нче бүлек. Җир кишәрлеге турында мәгълүмат | |
| 4.1. Капиталь төзелеш объекты булган җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) кадастр номеры <11>: | |
| 5 нче бүлек. Капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп кору өчен нигез булган төзелешкә рөхсәт турында белешмәләр | |
| 5.1. Төзелешкә рөхсәт алу датасы: | |
| 5.2. Төзелешкә рөхсәт номеры: | |
| 5.3. Төзелешкә рөхсәт биргән орган (оешма) атамасы: | |
| 6 нчы бүлек. Капиталь төзелеш объектының фактик күрсәткечләре һәм техник план турында белешмәләр <12> | |
| 6.X. Проект документларында каралган капиталь төзелеш объектының исеме <13>: | |
| 6.X.1. Капиталь төзелеш объектының төре <14>: | |
| 6.X.2. Объектның билгеләнеше <15>: | |
| 6.X.3. Үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының кадастр номеры <16>: | |

| | |
|---|---|
| 6.X.4. Төзелеш мәйданы (кв. м) <17>: | |
| 6.X.4.1. Капиталь төзелеш объектының бер өлешен төзү мәйданы (кв.м) <18>: | |
| 6.X.5. Мәйданы (кв. м) <19>: | |
| 6.X.5.1. Капиталь төзелеш объектының бер өлешенең мәйданы (кв.м) <20>: | |
| 6.X.6. Торак булмаган биналар мәйданы (кв. м): | |
| 6.X.7. Торак биналарның гомуми мәйданы (балконнарны, лоджияләрне, верандаларны һәм террасаларны исәпкә алып) (кв. м): | |
| 6.X.7.1. Торак биналарның гомуми мәйданы (балконнар, лоджияләр, верандалар һәм террасалардан тыш) (кв.м): | |
| 6.X.8. Бүлмәләр саны (данә): | |
| 6.X.9. Торак булмаган бүлмәләр саны (данә): | |
| 6.X.10. Торак булмаган бүлмәләр саны (данә): | |
| 6.X.11. шул исәптән, фатирлар (данә): | |
| 6.X.12. Машина урыннары саны (данә): | |
| 6.X.13. Катлар саны: | |
| 6.X.14. шул исәптән, җир асты катлары саны: | |
| 6.X.15. Сыйдырышлык (кеше): | |
| 6.X.16. Биеклеге (м): | |
| 6.X.17. Энергетика ягыннан нәтиҗәлелек классы (булган очракта) <21>: | |
| 6.X.18. Башка күрсәткечләр <22>: | |
| 6.X.19. Техник планны әзерләү датасы: | |
| 6.X.20. Техник планны әзерләгән | |

| | |
|---|---|
| кадастр инженерының индивидуаль шәхси счет номеры: | |
| 7 нче бүлек. Линия объектының фактик күрсәткечләре һәм техник план турында белешмәләр <23> | |
| 7.X. Проект документларында каралган линия объектының исеме <24>: | |
| 7.X.1. Үзгәртеп корылган линия объектының кадастр номеры: | |
| 7.X.2. Озынлыгы (м) <25>: | |
| 7.X.2.1. Линия объекты кишәрлегенең яки бер өлешенең озынлыгы (м) <26>: | |
| 7.X.3. Категориясе (классы): | |
| 7.X.4. Егәрлеге (үткәрү сәләте, йөк әйләнеше, хәрәкәт ешлыгы): | |
| 7.X.5. Тибы (кабельле электр тапшыру линиясе, электр тапшыру өчен һава линиясе, электр тапшыруның кабельле һава линиясе), электр тапшыру линияләренең көчәнеш дәрәҗәсе: | |
| 7.X.6. Башка күрсәткечләр <27>: | |
| 7.X.7. Техник планны әзерләү датасы: | |
| 7.X.8. Техник планны әзерләгән кадастр инженерының индивидуаль шәхси счет номеры: | |

| ______________________ | ______________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган (оешма) хезмәткәренең вазыйфасы) | (имза) | (инициаллар, фамилия) |

«___« _________20__ ел.

Мөһер урыны

--------------------

<1> Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт формасының тулысынча тутырылмаган (буш) бүлекләре мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган объектны файдалануга кертүгә рөхсәт составына кертелми. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт формасын тутырганнан соң һәм аны комплектлаганнан соң объектны файдалануга кертүгә

рөхсәтнең һәр битендә өске уң як почмакта «бит ___» кыры куела, анда 1 башлап, битнең тиешле тәртип саны куеп барыла.
<2> Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү датасы күрсәтелә. Дата гарәр саннары белән ДД.ММ.ГГГГ форматында күрсәтелә, андагы хәрефләр түбәндәгеләрне аңлата: ДД - көне, ММ - ае, ГГГГ - елы. Шул ук вакытта беренчесеннән башлап тугызынчысына кадәр, көне һәм (яки) ае икешәр сан белән күрсәтелә.
<3> Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы орган (оешма) тарафыннан бирелгән объектны файдалануга кертүгә рөхсәт номеры күрсәтелә, аның структурасы А-Б-В-Г, биредә:
А - төзелгән (үзгәртеп корылган) капиталь төзелеш объекты урнашкан территориянең кадастр округы номеры (ике урынлы) Объект ике һәм аннан күбрәк кадастр округлары территориясендә урнашкан очракта, «0» номеры күрсәтелә;
Б - төзелгән (үзгәртеп корылган) капиталь төзелеш объекты урнашкан территориянең кадастр районы номеры. Объект ике һәм аннан күбрәк кадастр районнары территориясендә урнашкан очракта, «0» номеры күрсәтелә;
В - объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы орган (оешма) тарафыннан бирелгән объектны файдалануга кертүгә рөхсәтнең тәртип номеры;
Г - объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү елы (тулысынча).
Номерның состав өлешләре бер-берсеннән «-» тамгасы белән аерыла. Санлы индекслар гарәп саннары белән билгеләнә.
Федераль башкарма хакимият органнары, «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе өчен номер ахырында мондый органның, оешманың үзләре тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә торган шартлы билгеләре күрсәтелә (булган очракта).
<4> Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы яисә Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы исеме яиә объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы оешманың исеме күрсәтелә: «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе.
<5> Вәкаләтле орган (оешма) тарафыннан объектны файдалануга кертүгә рөхсәткә үзгәрешләр яисә объектны файдалануга кертүгә рөхсәткә төзәтүләр кертү турында соңгы тапкыр кабул карар кабул итү датасы күрсәтелә, объектны файдалануга кертүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертелсә яисә объектны файдалануга кертүгә рөхсәттә җибәрелгән хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтүләр башкарылган очракта. Капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт датасы үзгәрми.
<6> Ата исеме булган очракта күрсәтелә.
<7> Төзүче шәхси эшкуар булган очракта тутырыла.

<8> Төзүче юридик зат булган очракта, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 54 статьясы нигезендә оешманың тулы исеме күрсәтелә.
<9> Капиталь төзелеш объектын төзү (үзгәртеп кору) башкаруга нигез булган төзелешкә рөхсәт нигезендә күрсәтелә.
<10> 3.3.1 - 3.3.7 юлларда капиталь төзелеш объектының адресы күрсәтелә, булмаган очракта – тиешле юлларны тутыру юлы белән капиталь төзелеш объекты урнашкан урын күрсәтелә; линия объектлары өчен мондый линия объектлары төзелгән территорияләрнең Россия Федерациясе субъекты(лары) һәм муниципаль берәмлек(ләр) атамасы рәвешендә урнашу урыны күрсәтелә. Линия объектларын үзгәртеп корган очракта, линия объектлары үзгәртеп корылган территорияләрнең Россия Федерациясе субъекты(лары) һәм муниципаль берәмлек(ләр) атамасы рәвешендә урнашу урыны күрсәтелә.
Капиталь төзелеш объектының адресы яисә урыны турындагы белешмәләр Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2015 елның 5 ноябрендәге 171н номерлы боерыгы белән расланган Адрес реквизитлары сыйфатында файдаланыла торган планлаштыру структурасы элементлары, урам-юл челтәре элементлары, адресация объектлары элементлары, биналар (корылмалар) типлары исемлеге һәм Адрес ясаучы элементларның кыскартылган исемнәре нигезендә тутырыла.
<11> Проект документациясендә каралган барлык капиталь төзелеш объектларына, шул исәптән мөлкәт комплексы, бердәм күчемсез комплекс буларак яисә катлаулы объект составына керүче объектларга (берничә капиталь төзелеш объектыннан торган) карата тутырыла. Линия объектына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт биргәндә, тутыру мәҗбүри түгел.
<12> Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт формасының 6 нчы бүлегендәге юллары файдалануга кертелә торган, проект документларында каралган, шул исәптән предприятие составына мөлкәт комплексы, бердәм күчемсез комплекс буларак керүче яки катлаулы объект составына керүче (берничә капиталь төзелеш объектыннан торган объект) һәр капиталь төзелеш объектына карата тутырыла.
13> 6.Х - 6.Х.20 юлларны тутырганда юл номерларында «Х» тамгасы урынына проект документларында каралган, шул исәптән предприятие составына мөлкәт комплексы, бердәм күчемсез комплекс буларак керүче яки катлаулы объект составына керүче (берничә капиталь төзелеш объектыннан торган объект) һәр капиталь төзелеш объектына карата аны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы орган (оешма) итеп аркылы нумерация ярдәмендә, 1 башлап, әлеге юллар мәгънәсе кайсына караса, шул капиталь төзелеш объектының тәртип саны күрсәтелә. Проект документлары белән бер объектны төзү, үзгәртеп кору каралган булса, 6Х юлындагы күрсәткечләр тутырылмый.
<14> Капиталь төзелеш объектларының бер төре күрсәтелә: бина, төзелеш, корылма.
<15 > «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге

218-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясындагы 5 өлешенең 9 пунктында каралганнар исәбендәге объектның объектны файдалануга кертүгә рөхсәт әзерләү датасына файдалану өчен билгеләнеше күрсәтелә.

<16> Үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының кадастр номеры күрсәтелә. Мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкарылган очракта, мондый объектның конструктив һәм куркынычсызлыгының башка үзенчәлекләренә кагылган очракта, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында исәпкә алынган мәдәни мирас объектының кадастр номеры күрсәтелә.

<17> Капиталь төзелеш объектының файдаланылырга кертелергә яисә автоном файдаланылырга мөмкин булган төзелеш, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, ягъни бу капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яки үзгәртеп коруга бәйсез рәвештә (алга таба әлеге искәрмәдә – этап), 6.X.4 юлда мондый капиталь төзелеш объектының элек файдалануга тапшырылган этапларына һәм файдалануга кертелә торган этапка туры килә торган капиталь төзелеш объектының төзелеш мәйданы күрсәтелә.

<18> Капиталь төзелеш объектының файдаланылырга кертелергә яисә автоном файдаланылырга мөмкин булган төзелеш, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта тутырыла, ягъни бу капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яки үзгәртеп коруга бәйсез рәвештә (алга таба әлеге искәрмәдә – этап). 6.X.4.1 юлда файдалануга кертелә торган этапның төзелеш мәйданы күрсәтелә.

<19> Капиталь төзелеш объектының файдаланылырга кертелергә яисә автоном файдаланылырга мөмкин булган төзелеш, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, ягъни бу капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яки үзгәртеп коруга бәйсез рәвештә (алга таба әлеге искәрмәдә – этап), 6.X.5 юлда мондый капиталь төзелеш объектының элек файдалануга тапшырылган этапларына һәм файдалануга кертелә торган этапка туры килә торган капиталь төзелеш объектының мәйданы күрсәтелә.

<20> Капиталь төзелеш объектының файдаланылырга кертелергә яисә автоном файдаланылырга мөмкин булган төзелеш, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта тутырыла, ягъни бу капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яки үзгәртеп коруга бәйсез рәвештә (алга таба әлеге искәрмәдә – этап). 6.X.5.1 юлда файдалануга кертелә торган этапның мәйданы күрсәтелә.

<21> Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнар нигезендә билгеләнә торган энергетика нәтиҗәлелеге классын бирү мәҗбүри булган капиталь төзелеш объектларына карата күрсәтелә.

<22> Булган очракта, мондый объектның дәүләт кадастр исәбен башкару өчен

кирәкле күләмдә капиталь төзелеш объектының төп характеристикалары күрсәтелә (күләме, тирәнлеге, яту тирәнлеге), шулай ук югарыда күрсәтелмәгән, капиталь төзелеш объектының башка характеристикалары да мәдәни мирас объектына карата күрсәтелә, әгәр мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкарганда мондый объектның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгы буенча конструктив һәм башка характеристикаларга кагылынса.

<23> Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт формасының 7 нче бүлегендәге юллары файдалануга кертелә торган, проект документларында каралган, шул исәптән предприятие составына мөлкәт комплексы, бердәм күчемсез комплекс буларак керүче яки катлаулы объект составына керүче (берничә капиталь төзелеш объектыннан торган объект) һәр линия объектына карата тутырыла.

24> 7.X - 7.X.8 юлларны тутырганда юл номерларында «X» тамгасы урынына проект документларында каралган, шул исәптән предприятие составына мөлкәт комплексы, бердәм күчемсез комплекс буларак керүче яки катлаулы объект составына керүче (берничә капиталь төзелеш объектыннан торган объект) һәр линия объектына карата аны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы орган (оешма) итеп аркылы нумерация ярдәмендә, 1 башлап, әлеге юллар мәгънәсе кайсына караса, шул капиталь төзелеш объектының тәртип саны күрсәтелә. Проект документлары белән бер объектны төзү, үзгәртеп кору каралган булса, 7.X юлындагы күрсәткечләр тутырылмый.

<25> Линия объектының файдаланылырга кертелергә яисә автоном файдаланылырга мөмкин булган төзелеш, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, ягъни бу объектның башка өлешләрен төзүгә яки үзгәртеп коруга бәйсез рәвештә (алга таба әлеге искәрмәдә – этап), 7.X.2 юлда мондый линия объектының элек файдалануга тапшырылган этапларына һәм файдалануга кертелә торган этапка туры килә торган линия объектының озынлыгы күрсәтелә.

Үзенә карата линия объектының участогын (участокларын) яки өлешен (өлешләрен) үзгәртүне күздә тоткан үзгәртеп кору гамәлгә ашырылган линия объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, 7.X.2 юлында элегрәк кертелгән барлык һәм файдалануга кертелә торган линия объекты участокларының яисә өлешләренең озынлыклары күрсәтелә.

<26 > Файдалануга тапшырылырга яисә автоном файдаланылырга мөмкин булган линиянең бер өлешен төзү, үзгәртеп кору булган төзелеш, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта тутырыла, ягъни әлеге объектның башка өлешләрен төзүгә яисә үзгәртеп коруга бәйсез рәвештә (алга таба, әлеге искәрмәдә – этап), яисә үзенә карата линия объектының участогын (участокларын) яисә өлешен (өлешләрен) үзгәртүне күздә тоткан, линия объектының озынлыгын үзгәртүгә китереп чыгарган үзгәртеп кору

гамәлгә ашырылган линия объектын файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта тутырыла.
Бу очракларда 7.Х. 2.1 юлда файдалануга кертелә торган этапның озынлыгы яки линия объектының тиешле участогының яки өлешенең озынлыгы күрсәтелә.
<27> Булса, мондый объектның дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә линия объектының төп характеристикалары күрсәтелә (күләме, тирәнлеге, яткан тирәнлеге), шулай ук югарыда күрсәтелмәгән, линия объектының характеристикалары да күрсәтелергә мөмкин.».